ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.03.2023 г. Заинск № 178

**"2023 елга салым салынырга тиешле гражданнар кеременең һәм мөлкәте хакының чик күрсәткечләрен раслау турында"**

«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. 2023 елга гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын арендалау шартнамәләре буенча аларга торак урыннары бирүгә мохтаҗ дип тану турында карар кабул итү өчен гражданнарның салым салынырга тиешле керемнәре һәм мөлкәтенең түбәндәге максималь күләмнәрен билгеләргә:
1.1. Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләменең максималь күрсәткече - 24012,37 сум.
1.2. Гаилә әгъзаларының яки ялгыз яшәүче гражданның милкендәге салым салынырга тиешле мөлкәтнең максималь бәясе:
- ялгыз яшәүче граждан өчен - 714553,80 сум;
- ике кешедән торган гаилә өчен – 1429107,61 сум;
- өч кешедән торган гаилә өчен – 2143661,41 сум;
-дүрт кешедән торган гаилә өчен – 2858215,21 сум;
-биш кешедән торган гаилә өчен – 3572769,02 сум;
-алты кешедән торган гаилә өчен – 4287322,82 сум;
-җиде кешедән торган гаилә өчен – 5001876,62 сум;
-сигез кешедән торган гаилә өчен – 5716430,42 сум;
-тугыз кешедән торган гаилә өчен – 6430984,23 сум;
-ун кешедән торган гаилә өчен – 7145538,03 сум.
2. "Салым салынырга тиешле гражданнар кеременең һәм мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен раслау турында" 2022 елның 28 мартындагы 154 номерлы

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Зәй муниципаль районының http://zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат http://pravo.tatarstan.ru порталында урнаштырырга.

4. Уртак торак-көнкүреш комиссиясенә гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип таныганда әлеге карарның 1.1, 1.2 пунктлары күрсәткечләрен файдаланырга.

5. Карар рәсми рәвештә басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Р.М.Хаҗиповка йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

С.А.Филюшина
Юрист